**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
Камско-Устьинский
муниципальный район
**Исполнительный комитет**
**Клянчеевского**
**сельского поселения**

**Камско-Устьинский район,**
**с. Клянчеево, 422836**
**тел./факс 8(84377)33-4-31**
**ОГРН 1061672017990**
**ИНН/КПП 1622004620/162201001**

**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
Кама Тамагы муниципаль
районының
**Келәнче**
**авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**
**Кама Тамагы районы,**
**Келәнче авылы, 422836**
**тел./факс 8(84377)33-4-31**
**ОГРН 1061672017990**
**ИНН/КПП 1622004620/162201001**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 26 июленнән №13

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге башкарма комитетынын 31.03.2020 № 12 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан һәм (яисә) муниципаль программаларга карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла».

1.2. 12 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына һәм (яисә) муниципаль программаларга карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе».

1.3. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана».

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Келәнче авылы, Г.Тукай ур., 35 йорт;
-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәки авылы, Фрунзе ур., һәм әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Келәнче җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе : Д.А.Кадыров.